| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.10.2024 с.Старое Дрожжаное № 432

2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга беркетелгән норматив чыгымнарны расларга.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына мәгариф оешмаларын финанслауны мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 нче пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының
2024 елның
"16" октябрендәге 432
номерлы карары
белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 119 559 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 181 658 |

Эшләр идарәчесе: Сабир Д.Р. Сабирзянова